| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>УЛЬЯНКОВО АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.10.2022 Ульянково ав. № 54

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Башлыгының һәм муниципаль хезмәткәрләренең айлык акчалата түләү күләмнәрен һәм вазыйфаи окладларын арттыру турында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнен үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы сайланулы органнары әгъзаларының, рәис урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Советынын 2018 елның 30 апрелендәге 89 номерлы .« Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфаны биләүче затларга хезмәт хакы күләме, айлык һәм башка өстәмә түләүләр нормативлары һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» карары белән билгеләнгән тәртиптә каралганча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре биләгән вазыйфалары нигезендә алар тарафыннан билгеләнә торган муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә ай саен акчалата түләү күләмнәрен һәм вазыйфаи окладларның күләмнәрен 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Әлеге карар аның рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Ульянковского сельского поселения Ульянково авыл җирлеге советы

Кайбыч муниципаль районы
авыл җирлеге Ульянково Башлыгы Ф.А.Сундурова